**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР |
|---|---|
| от 08.09.2020 | № 687 |

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә авыл территорияләрен комплекслы үстерү» муниципаль Программасын раслау турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында», 2006 елның 29 декабрендәге 264-ФЗ номерлы «Авыл хуҗалыгын үстерү турында» Федераль законнары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2002 елның 14 июлендәге 717 номерлы «Авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу Дәүләт программасы турында» карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 8 апрелендәге 235 номерлы «2013 - 2025 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» Дәүләт программасын раслау турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты, КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә авыл территорияләрен комплекслы үстерү» муниципаль Программасын расларга (Кушымта).
2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Эшләр белән идарәчесе Г.Ф. Сабировага йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин

Кушымта

Расланган
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 08 сентябрендәге 687 нче номерлы карары белән

**Муниципаль программаның паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | ТР Биектау муниципаль районы территориясендә авыл территорияләрен комплекслы үстерү |
| Программа әзерләү өчен нигез (исеме, хокукый актның номеры һәм датасы) | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 8 апрелендәге 235 номерлы «2013 - 2025 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» Дәүләт программасын раслау турында» карары |
| Программаның төп эшләүчеләре | ТР Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге;<br>ТР Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының торак бүлү секторы;<br>«ТР Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МУ;<br>«ТР Биектау муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» МУ;<br>«ТР Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният бүлеге» МКУ;<br>«Биектау үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;<br>Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе |
| Программаны башкаручылар | РТ Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаның максаты | Авыл территорияләрендә яшәү өчен уңайлы шартлар тудыру һәм авылга, авыл тормышына уңай караш тәрбияләү |
| Программаның бурычлары | Авыл халкының һәркем ала алган уңайлы торакка ихтыяҗларын тәэмин итү;<br>авылны социаль-инженерлык уңайлыклар белән тәэмин итү дәрәҗәсен күтәрү һәм автомобиль юллары белән тәэмин итү;<br>авыл территорияләрендә хезмәт базарын (кадрлар |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | потенциалын) үстерү | | | | | | | |
| Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары | 2020 - 2025 еллар | | | | | | | |
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары | | | | | | |
| | | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 | Тормышка ашыру чорына |
| | Муниципаль бюджет | 29,2 | 83,5 | 104,4 | 125,3 | 146,2 | 167,1 | 655,7 |
| | Федераль бюджет | 53356,4 | 54875,3 | 55844,2 | 57812,9 | 59871,8 | 59750,6 | 341421,2 |
| | Республика бюджеты | 2982,2 | 4806,3 | 6507,8 | 7209,4 | 7209,4 | 8612,5 | 38029,1 |
| | Башка чыганаклар | 555,4 | 1586,8 | 1983,6 | 2380,3 | 2777,1 | 3173,7 | 555,4 |
| | Баолыгы | 56923,2 | 61351,9 | 64440 | 67527,9 | 70616 | 71703,9 | 392562,9 |
| | Татарстан Республикасы бюджетыннан программа юнәлешләре буенча бүлеп бирелә торган акчаларның суммасына чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы нигезендә ел саен төгәллек кертеләчәк | | | | | | | |

| | |
|---|---|
| Программаны гамәлгә ашыруның көтелә торган нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре | Файдалануга кертеләчәк:<br>авыл территорияләрендә яшәүче гражданнар өчен, гомуми мәйданы 500 мең кв. метр булган торак;<br>10 километр озынлыктагы локаль сууткәргечләр;<br>авыл территорияләрендә урнашкан торак пунктларның иҗтимагый әһәмиятле объектларына, җитештерү һәм продукцияне эшкәртү объектларына 6,3 километр озынлыктагы гомуми файдаланудагы автомобиль юллары.<br>компактлы торак төзелеше өчен мәйданчыкларны комплексly төзекләндерү проектлары гамәлгә ашырылачак авыл территорияләрендә урнашкан торак пунктлар саны 3 берәмлек тәшкил итәчәк;<br>инженерлык инфраструктурасы объектлары белән һәм авыл территорияләрендә урнашкан мәйданчыкларны төзекләндерү буенча гамәлгә ашырылган проектлар саны компакт торак төзелеше өчен 2 берәмлек тәшкил итәчәк;<br>авыл территорияләрен төзекләндерү буенча гамәлгә ашырылган проектлар саны 47 берәмлек тәшкил итәчәк; |
| Программаны гамәлгә ашыруны контрольдә тотуны оештыру системасы | «РТ Биектау муниципаль районы Контроль-хисап палатасы» МКУ |

## I. Программаны гамәлгә ашыру өлкәсе, төп проблемалар, аларны хәл итүне бәяләү һәм үсеш фаразы

Биектау муниципаль районының хәзерге этапта үсеше дәүләт тарафыннан авыл территорияләрен үстерүгә игътибар арту белән характерлана.

2014 елдан Биектау муниципаль районында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 15 июлендәге 598 нче номерлы «2014 - 2017 елларга һәм 2020 елга кадәрге чорга авыл территорияләрен тотрыклы үстерү» федераль максатчан программасы турында» карары белән расланган «2014 - 2017 елларга һәм 2020 елга кадәр чорга авыл территорияләрен тотрыклы үстерү» федераль максатчан программасы гамәлгә ашырылды. Программа буенча 11 юнәлеш, шул исәптән инженерлык челтәрләре, социаль-мәдәни, сәламәтлек саклау, торак һәм башкалар буенча чаралар финансланган. 2014 елдан әлеге программа кысаларында авыл җирлегендә эшләүче яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары гамәлгә ашырылды. 2006 елдан алып 2013 елның 1 гыйнварына кадәр дәүләт ярдәме алган кешеләр саны 117 гаилә тәшкил иткән, 15,33 мең кв. метр күләмендә торак тапшырылган. Авыл җирлегендә торак йортларны (фатирларны) челтәр газы белән газлаштыру дәрәҗәсе 99,1 процент тәшкил итте, авыл халкының эчәргә яраклы су белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе - 78,2 процентка кадәр.

Авылда яшәү шартларын яхшырту, башка факторлар белән беррәттән, аграр өлкәдә инвестицион активлыкны арттыруга, социаль ситуацияне яхшыртуга ярдәм итте.

Шуның белән бергә гамәлгә ашырылган чаралар авыл территорияләренең икътисадый потенциалын тулысынча һәм нәтиҗәле файдалану һәм авыл халкының тормыш сыйфатын күтәрү өчен җитәрлек түгел.

Территорияләрне тотрыклы үстерү чараларын гамәлгә ашыруда дәүләтнең ролен көчәйтүнең максатка ярашлылыгы түбәндәгеләргә нигезләнгән:

авыл территорияләрен тотрыклы үстерүнең максатчан билгеләнешләренең авылда тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын күтәрү, икътисадның аграр һәм башка секторларын

икътисадый үстерү өчен социаль нигезләр булдыру өлешендә Россиянең социаль-икътисадый үсеш өстенлекләре белән үзара бәйләнеше белән;

авыл территорияләрендәге социаль проблемаларның аларны хәл итүгә системалы якын килүне таләп итә торган озак сроклы характеры;

дәүләт ярдәмен җәлеп итүне таләп итә торган авыл проблемалы мәсьәләләрен хәл итүнең чыгымнарның югары дәрәҗәсе.

Әлеге ярдәмче программа максатларына ирешү авыл территорияләрендә яшәүнең уңайлылыгын күтәрүгә, агросәнәгать комплексында һәм тулаем авыл икътисадында инвестиция активлыгын үстерү өчен уңай шартлар булдыруга ярдәм итәчәк.

Ярдәмче программа максатларына ирешү өчен авыл территорияләрен комплекслы үстерү өлкәсендә куелган бурычларны хәл итү кирәклегенә нигез булып тора:

авыл җирлегендә хезмәт потенциалын формалаштыруга сизелерлек йогынты ясый торган уңайсыз демографик ситуация;

авыл территорияләрендә социаль һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары белән тәэмин ителешнең түбән дәрәҗәсе;

авыл җирлегендә торак базарын үстерү дәрәҗәсе һәм авыл халкы өчен торак шартларын яхшырту мәсьәләсен хәл итү мөмкинлеге түбән булу;

яшәү тирәлеге буларак авыл җирлеге җәлеп итмәве һәм миграция артуы, шул исәптән авыл яшьләре арасында;

авыл халкының социаль активлыгы түбән дәрәҗәсе;

авыл территорияләрен үстерү перспективаларына җәмгыятьтә уңай карашлар булмау.

Программа Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 31 маендагы 696 номерлы «Россия Федерациясенең «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» карары белән расланган «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы нигезендә эшләнгән.

## II. Ярдәмче программаның максатлары, бурычлары һәм төп көтелгән соңгы нәтиҗәләре, аны гамәлгә ашыру сроклары

Программаның максаты булып авыл территорияләрендә яшәү өчен уңайлы шартлар тудыру һәм авылга һәм авыл тормышына уңай мөнәсәбәт формалаштыру тора.

Максатларга ирешү өчен авыл халкының һәркем алырлык уңайлы торакка булган ихтыяҗларын канәгатьләндерү, авылның социаль-инженерлык төзеклеге дәрәҗәсен күтәрү һәм автомобиль юллары белән тәэмин итү бурычларын хәл итәргә кирәк.

Булган потенциалны нәтиҗәле файдалану, дәүләт ярдәме һәм бюджеттан тыш инвестицияләрне җәлеп итү куелган максатларга ирешергә мөмкинлек бирә.

Куелган максатларга һәм бурычларга ирешү тәэмин итәчәк:

авыл территорияләрендә яшәүче гражданнар өчен, гомуми мәйданы 500 мең кв. метр булган торакны файдалануга кертү; 10 километр озынлыктагы локаль сүүткәргечләрен файдалануга кертү; авыл территорияләрендә урнашкан торак пунктларның иҗтимагый әһәмиятле объектларына, җитештерү һәм продукцияне эшкәртү объектларына 6,3 километр озынлыктагы гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын кертү; компактлы торак төзелеше өчен 2 берәмлек мәйданчыкларны комплекслы төзекләндерү проектларын гамәлгә ашыру; компакт торак төзелеше өчен 3 берәмлек инженерлык инфраструктурасы объектлары белән һәм авыл территорияләрендә урнашкан мәйданчыкларны төзекләндерү буенча проектлар гамәлгә ашыру; авыл территорияләрен төзекләндерү буенча 47 берәмлек проектны гамәлгә ашыру;

Программа нәтиҗәләрен бәяләүнең максатлары, бурычлары, индикаторлары төп чаралар киселешендә 19 нчы таблицада китерелгән.

Программаны гамәлгә ашыру срогы: 2020 - 2025 еллар.

## III. Программаның төп чараларына характеристика

Программа түбәндәге чараларны үз эченә ала:

авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту һәм торак урынын наем шартнамәсе буенча бирелгән торак төзелеше;

авыл җирлегендә урнашкан торак пунктларны комплекслы төзекләндерү, социаль һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары белән тәэмин итү, шул исәптән авыл территорияләрен төзекләндерү чараларын гамәлгә ашыру, авыл территорияләрендә газлаштыру, су белән тәэмин итүне үстерү, авыл территорияләрендә компактлы торак төзелеше өчен мәйданчыкларны комплекслы төзекләндерү проектларын гамәлгә ашыру, авыл территорияләрендә урнашкан инженерлык инфраструктурасы объектларын төзекләндерү һәм компактлы торак төзелеше өчен мәйданчыкларны төзекләндерү проектларын гамәлгә ашыру, авыл территорияләрендә урнашкан авыл торак пунктларының иҗтимагый әһәмиятле объектларына, җитештерү һәм продукция эшкәртү объектларына илтүче гомуми файдаланудагы каты өслекле автомобиль юллары челтәрен үстерү, авыл территорияләрен (авыл агломерацияләрен) комплекслы үстерү проектларын гамәлгә ашыру.

Авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту чараларының максатлары - авыл халкын һәркем сатып алырлык уңайлы торак белән тәэмин итү, авыл җирлегендә яшь белгечләрне җәлеп итү һәм калдыру.

Авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту мөмкинлеген арттыруны түбәндәге юллар белән гамәлгә ашыру күз алдында тотыла:

авыл территорияләрендә торак төзүгә һәм сатып алуга федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты һәм муниципаль районнарның җирле бюджеты акчалары исәбеннән социаль түләүләр бирү;

наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак төзелешен федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты һәм муниципаль районнарның җирле бюджеты акчалары исәбеннән алга таба сатып алу хокукы белән үзара финанслашу;

ташламалы ипотека торак кредитлавы һәм ана (гаилә) капиталы механизмнарын төзегәндә (сатып алганда) файдалану;

торак өлкәсендә инвестиция активлыгын стимуллаштыру нигезендә авыл җирлегендә торак төзелеше күләмнәрен арттыру.

Авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшыртуга һәм торак урынны наем шартнамәсе буенча бирелгән торак төзелешенә муниципаль районнар бюджетларына субсидияләр бирү һәм бүлү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган кагыйдәләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

Авыл җирендә урнашкан торак пунктларны социаль объектлар һәм инженерлык инфраструктурасы белән комплекслы төзекләндерү чараларын гамәлгә ашыру түбәндәге юнәлешләр буенча гамәлгә ашырыла:

авыл территорияләрен төзекләндерү;

авыл территорияләрендә газлаштыруны үстерү;

авыл территорияләрендә су белән тәэмин итүне үстерү;

авыл территорияләрендә компактлы торак төзелешенә мәйданчыкларны комплекслы төзекләндерү проектларын гамәлгә ашыру;

инженерлык инфраструктурасы объектлары белән тәэмин итү һәм авыл территорияләрендә урнашкан мәйданнарны компактлы торак төзелеше өчен төзекләндерү проектларын гамәлгә ашыру;

гомуми файдаланудагы автомобиль юллары челтәреннән авыл территорияләрендә урнашкан авыл торак пунктларының иҗтимагый әһәмиятле объектларына, продукция җитештерү һәм эшкәртү объектларына илтүче гомуми файдаланудагы каты өслекле автомобиль юллары челтәрен үстерү;

авыл территорияләрен (авыл агломерацияләрен) комплекслы үстерү проектларын гамәлгә ашыру.

Комплекслы төзелеш проектлары агросәнәгать комплексының тизләтелгән үсеш урыннарында, шул исәптән гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектлары территорияләрендә, агросәнәгать җитештерүенең заманча технологияләре өлкәсендә белемгә ия яшь белгечләрне җәлеп итеп гамәлгә ашырылырга тиеш.

Авыл территорияләрендә урнашкан торак пунктларның социаль һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары белән комплекслы төзекләндерүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү һәм бүлү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган кагыйдәләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

## IV. Программаны ресурслар белән тәэмин итү һәм аны нигезләү

Программаны гамәлгә ашыруны финанслауның гомуми күләме 392562,9 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән федераль бюджет акчаларын җәлеп итүгә планлаштырыла торган акчалар исәбеннән - 341421,2 мең сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән - 38029,1 мең сум, муниципаль районнарның җирле бюджетлары исәбеннән - 655,7 мең сум, бюджеттан тыш чыганаклар исәбеннән - 12456,9 мең сум.

Программа кысаларында гражданнарны торак белән тәэмин итүдә дәүләт ярдәме күрсәтү, авыл җирлегендә социаль һәм инженерлык инфраструктурасының түбәндәге объектлары челтәрен үстерү карала: бүлүче газ челтәрләрен, локаль суүткәргечләрне, авыл территорияләрендә урнашкан авыл торак пунктларының иҗтимагый әһәмиятле объектларына, продукция җитештерү һәм эшкәртү объектларына гомуми файдаланудагы автомобиль юллары челтәреннән алып баручы каты өслекле гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын, шулай ук компактлы торак төзелеше өчен мәйданчыкларны комплекслы төзекләндерү проектларына, инженерлык инфраструктурасы объектлары белән төзекләндерү һәм компактлы торак төзелешенә мәйданчыкларны төзекләндерү проектларына, авыл территорияләрен (авыл агломерацияләрен) комплекслы үстерү проектларына дәүләт ярдәме күрсәтү, алар төзелеш территориясендә гражданнар яшәеше өчен уңайлы шартлар тудыру максатларында җир кишәрлекләрен комплекслы үзләштерүне һәм җир кишәрлекләрен комплекслы үстерү проектларын күздә тота.

Дәүләт ярдәмен гамәлгә ашыру муниципаль районнарда кабул ителгән авыл территорияләрен комплекслы үстерү максатчан программалары нигезендә күздә тотыла, алар территориаль планлаштыру документлары нигезендә агросәнәгать комплексын үстерүнең перспектив планнары белән координациядә эшләнергә тиеш.

Күрсәтелгән максатчан программалар үз эченә кертергә тиеш:

агросәнәгать комплексы өлкәсендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен авыл җирендә уңайлы инфраструктура шартлары булдыруга юнәлдерелгән чаралар;

авыл территорияләрендә урнашкан торак пунктларның социаль-инженерлык төзелеше объектлары реестры һәм, территориаль планлаштыру документлары нигезендә, агросәнәгать комплексының төзелгән (төзелә торган) объектларына өстәмә рәвештә, компактлы торак төзелешенә мәйданчыкларны комплекслы төзекләндерү проектлары;

чаралар гамәлгә ашырыла торган авыл җирендә агросәнәгать комплексы оешмаларында өстәмә югары технологияле эш урыннары булдыру;

социаль һәм инженерлык инфраструктурасы объектларын төзегәндә заманча технологияләр куллану;

инфраструктура потенциалын һәм инвестиция проектларын гамәлгә ашыру үзенчәлекләрен исәпкә алып, авыл территорияләрендә урнашкан торак пунктларның социаль-инженерлык төзекләндерүнең комплекслылыгы;

ярдәмче программаны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетында һәм муниципаль районнарның җирле бюджетларында бюджет ассигнованиеләре булу;

ярдәмче программаны финанслау һәм гамәлгә ашыру өчен кирәкле норматив хокукый

база булу;

социаль һәм инженерлык инфраструктурасын комплекслы үстерү һәм авыл җирендә торак шартларын яхшырту максатларында бюджеттан тыш акчалар җәлеп итүне стимуллаштыру чаралары булу.

Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләрне муниципаль районнар арасында бирү һәм бүлү кагыйдәләре һәм программаны гамәлгә ашыру максатларында бирелә торган субсидияләр күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

## V. Программаны гамәлгә ашыруда хәвефләргә анализ, әлеге хәвефләр белән идарә чаралары тасвирламасы

Программаны гамәлгә ашыру хәвефләр белән бәйле, алардан төп куркынычлар булып торалар:

федераль законнар үзгәрүе;

программаны финанс белән тәэмин итүнең төрле чыганакларыннан финанслауның булмавы яисә тулысынча финансланмавы.

Программаны гамәлгә ашыру хәвефләре белән идарә итү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 31 маендагы 696 нчы номерлы "Авыл территорияләрен комплекслы үстерү" Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында” һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында" карары белән расланган "Авыл территорияләрен комплекслы үстерү" Россия Федерациясе дәүләт программасында каралган чараларны куллану нигезендә гамәлгә ашырылачак.

Ярдәмче
программа
паспортына
1 нче кушымта

**«Биектау муниципаль районы территориясендә авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Программасының максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары**

| Максатның исеме | Бурычның исеме | Программалар исеме | Төп чаралар исеме | Башкаручылар | Төп чараларны гамәлгә ашыру сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның аңлатмасы | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | База елы | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 |
| Авыл җирендә яшәү өчен уңайлы шартлар тудыру һәм авылга, авыл тормышына уңай караш тәрбияләү | Авыл халкын һәркем сатып ала алырлык һәм уңайлы торак белән тәэмин итү | Авыл территорияләрен комплекслы үстерү | Авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты | 2020-2025 | Авыл территорияләрендә (авыл агломерацияләрендә) яшәүче гражданнар өчен торакны файдалануга кертү - барлыгы, кв. метр, шул исәптән: | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| | | | | | | авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | торак урынын наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак төзү | - | - | - | - | - | - | - |
| | Авыл территориял әрен социаль һәм инженерлык төзекләндерү дәрәҗәсен күтәрү һәм автомобиль юллары белән тәэмин итү | Авыл территори яләрен комплексл ы үстерү | Авыл җирендә социаль һәм инженерлык инфраструк турасын үстерү һәм автомобиль юллары белән тәэмин итү | Татарстан Республика сы Биектау муниципал ь районы башкарма комитеты | 2020-2025 | Локаль сүүткәргечләрне гамәлгә кертү, км | - | - | 24,124 | - | - | - | - |
| | | | | | | Авыл торак пунктларының иҗтимагый әһәмиятле объектларына, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм эшкәртү объектларына илтүче автомобиль юлларын эксплуатацияләүгә кертү, км | 26 | 2,6 | 3,8 | 3,7 | 3,9 | 4,0 | 3,8 |
| | | | | | | Торак төзелеше өчен мәйданчыкларны, берәмлекләрне комплекслы төзекләндерү проектлары гамәлгә ашырылган авыл җирлегендә урнашкан торак пунктлар саны, берәмлек | **1** | 1 | 1 | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Компактлы торак төзелешенә авыл территорияләрендә урнашкан инженерлык инфраструктурасы объектлары белән тәэмин итү һәм мәйданчыкларны төзекләндерү буенча гамәлгә ашырылган проектлар саны, берәмлек | - | 1 | 1 | - | 1 | - | 1 |
| | | | | | | Авыл территорияләрен төзекләндерү буенча гамәлгә ашырылган проектлар саны, берәмлек | 24 | 24 | 20 | 18 | 21 | 19 | 20 |
| | | | | | | | | | | | | | |

**«Биектау муниципаль районы территориясендә авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Программасын гамәлгә ашыруны ресурслар белән тәэмин итү**

(мең сум)

| Бурычның исеме | Чараның исеме | Финанслау чыганагы | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Программа буенча барлыгы | барлыгы | 56923,2 | 61351,9 | 64440 | 67527,9 | 70616 | 71703,9 |
| | | федераль бюджет <*> | 53356,4 | 54875,3 | 55844,2 | 57812,9 | 59781,8 | 59750,6 |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | 2982,2 | 4806,3 | 6507,8 | 7209,4 | 7910,9 | 8612,5 |
| | | муниципаль районнарның җирле бюджеты | 29,2 | 83,5 | 104,4 | 125,3 | 146,2 | 167,1 |
| | | бюджеттан тыш чыганаклар | 555,4 | 1586,8 | 1983,6 | 2380,3 | 2777,1 | 3173,7 |
| Авыл халкын һәркем сатып алырга мөмкин булган һәм уңайлы торак белән тәэмин итү | Авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту | Федераль бюджет <*> | 1356,4 | 3 875,3 | 4 844,2 | 5 812,9 | 6 781,8 | 7 750,6 |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | 982,2 | 2 806,3 | 3 507,8 | 4 209,4 | 4 910,9 | 5 612,5 |
| | | муниципаль районнарның җирле бюджеты | 29,2 | 83,5 | 104,4 | 125,3 | 146,2 | 167,1 |
| | | бюджеттан тыш чыганаклар | 555,4 | 1 586,8 | 1 983,6 | 2 380,3 | 2 777,1 | 3 173,7 |
| | Торак урынын наем шартнамәсе буенча бирелгән торак төзелеше | федераль бюджет <*> | - | - | - | - | - | - |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | - | - | - | - | - | - |
| | | муниципаль | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | районнарның җирле бюджеты | | | | | | |
| | | бюджеттан тыш чыганаклар | - | - | - | - | - | - |
| Авыл территорияләр енең социаль һәм инженерлык төзекләндерү дәрәҗәсен күтәрү һәм автомобиль юллары белән тәэмин итү | Авыл җирендә социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү һәм автомобиль юллары белән тәэмин итү | федераль бюджет <*> | 8000 | 8000 | 8000 | 8000 | 8000 | 8000 |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | - | - | - | - | - | - |
| | | муниципаль районнарның җирле бюджеты | - | - | - | - | - | - |
| | | бюджеттан тыш чыганаклар | - | - | - | - | - | - |
| | авыл территорияләрен төзекләндерү чараларын гамәлгә ашыру | федераль бюджет <*> | 36000,00 | 35000,00 | 35000,00 | 36000,00 | 37000,00 | 36000,00 |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | - | - | 1000,00 | 1000,00 | 1000,00 | 1000,00 |
| | | муниципаль районнарның җирле бюджеты | - | - | - | - | - | - |
| | | бюджеттан тыш чыганаклар | - | - | - | - | - | - |
| | авыл территорияләрендә су белән тәэмин | федераль бюджет <*> | 8000 | 8000 | 8000 | 8000 | 8000 | 8000 |
| | | Татарстан | 2000 | 2000 | 2000 | 2000 | 2000 | 2000 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | итүне үстерү | Республикасы бюджеты | | | | | | |
| | | муниципаль районнарның җирле бюджеты | - | - | - | - | - | - |
| | | бюджеттан тыш чыганаклар | - | - | - | - | - | - |

<*> Федераль бюджет акчалары Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын уртак финанслау шартларында Татарстан Республикасы бюджетына җәлеп ителәчәк һәм биреләчәк, аларның күләмнәре ел саен Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары белән төзелгән килешүләр нигезендә билгеләнәчәк.